МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.03.2015 г.Казань № 135

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга яраштыру максатында, һәм шулай ук мониторинг нәтиҗәләрен исәпкә алып **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына (алга таба – Административ регламент) кертелә торган түбәндә теркәлгән үзгәрешләрне расларга.

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлегенә (Т.А.Апаев) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтына урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне министр урынбасары А.Д.Шәмсиевкә йөкләргә.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланган

19.03.2015 № 135

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензион контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

Административ регламентның 1.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«- экспертлар – контрольлек итү буенча чаралар үткәрүгә җәлеп итү максатында Министрлыкта аттестация үткән, кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату сферасында дәүләт лицензион контрольлеге өлкәсендә техник экспертиза уздыру буенча тәҗрибәгә, махсус белемгә ия, шәхси эшкуар булмаган гражданнар тарафыннан;

- эксперт оешмалар – Министрлык тарафыннан контрольлек итү буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителүче һәм Россия Федерациясенең милли аккредитация системасында аккредитация турындагы законнарга ярашлы рәвештә аккредитация үткән шәхси эшкуарлар, юридик затлар тарафыннан.»;

Административ регламентның 1.3 пунктында:

җиденче абзацны үз көчен югалтты дип танырга;

түбәндәге эчтәлектәге яңа унберенче, уникенче абзацлар белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) уздыруга вәкаләтле органнар, муниципаль контроль органнары тарафыннан контроль чаралары үткәрүгә җәлеп ителгән экспертларны аттестацияләү турында» 2014 елның 10 июлендәге 636нчы карары белән» (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 636нчы карары) («Россия Федерациясе Законнары җыелмасы», 21.07.2014, № 29, 4142 маддә);

Федераль салым хезмәтенең «Юридик затларга, шәхси эшкуарларга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына дәүләт теркәве уздырганда теркәү органына тапшырыла торган документларга карата таләпләрне һәм формаларны раслау турында» 2012 елның 25 гыйнварындагы ММВ-7-6/25@ номерлы боерыгы белән (алга таба – Россия ФСХнең 2012 елның 25 гыйнварындагы ММВ-7-6/25@ номерлы боерыгы) (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2012 елның 14 маенда теркәлгән, теркәлү номеры 24139, «Башкарма хакимиятнең федераль органнарының норматив актлары бюллетене», 2012 елның 20 октябре, № 44);»;

унберенче – унбишенче абзацларны унөченче – унҗиденче абзацлар дип санарга;

түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Дәүләт лицензия контроле өлкәсендә техник экспертиза үткәрү экспертларын аттестацияләү буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 24 декабрендәге 488нче боерыгы белән (хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru).»;

Административ регламентның 1.5 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Бары тик Министрлык тарафыннан бирелгән күрсәтмәне үтәү генә мәҗбүри таләпләрне бозу буенча ачыкланган хилафлыкны юкка чыгару турында кисәтүнең юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан үтәлүе срокларының узуы нигез булып торган планнан тыш тикшерү предметы булып тора ала.»;

Административ регламентның 1.6.2 пункты 13 подпунктын һәм 1.8 пункты 3 подпунктын, «тикшерүләр исәбе журналында» сүзләреннән соң, «, ул булган очракта» сүзләре белән тулыландырырга;

Административ регламентның 1.6.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 7 подпункт белән тулыландырырга:

«7) тикшерү, сынау, үлчәү үткәрү өчен әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү мохите объектларын тикшерү үрнәкләрен, продукция үрнәкләрен әлеге үрнәкләрне билгеләнгән формада алу турындагы һәм үрнәкләрне алуның милли стандартлары, кагыйдәләре һәм аларны тикшерү, сынау, үлчәү методлары, техник регламентлары яки алар үз көченә кергәнче гамәлдә булган башка норматив техник документлар һәм кагыйдәләр һәм тикшерү, сынау, үлчәү методлары тарафыннан билгеләнгән нормадан югарырак санда алу турындагы беркетмәне рәсмиләштермичә генә алырга.»;

Административ регламентның 1.7.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 5 подпункт белән тулыландырырга:

«5) тикшерүдә катнашуга Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкилне яки Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкилне җәлеп итәргә.»;

Административ регламентның 2.1.5 пунктының өченче абзацындагы «(мәгълүмат такталарында әлеге Регламент текстының аерым фрагментлары урнаштырыла)» сүзләрен юкка чыгарырга;

Административ регламентның 2.3 пунктында:

түбәндәге эчтәлектәге дүртенче абзац белән тулыландырырга:

«План буенча күчмә тикшерүләр уздыручы Министрлыкның вазыйфаи затларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озакка сузылырлык эзләнүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшеренүләр үткәрүнең зарурлыгына бәйле рәвештә, аерым очракларда план буенча күчмә

тикшерүләр уздыру сроклары министр тарафыннан озынайтылырга мөмкин, әмма егерме эш көненнән дә артыкка түгел, кече предприятиеләр өчен – илле сәгатьтән дә артыкка түгел, микропредприятиеләр өчен – унбиш сәгатьтән дә артыкка түгел.»;

дүртенче – бишенче абзацларны бишенче – алтынчы абзацлар дип санарга;

Административ регламентның 2.4.2 пункты 1 подпунктын «, бу очракта Министрлык тарафыннан бирелгән күрсәтмәне үтәү генә тикшерү предметы булып тора ала;» сүзләре белән тулыландырырга;

Административ регламентның 3 бүлегендәге 1 таблицаның 1.1 пункты 2 подпунктын һәм 1.2 пункты 2 подпунктын ( «Мәҗбүри таләпне формалаштыру» графасы) түбәндәге редакциядә бирергә:

«лицензиягә дәгъва кылучының һәм лицензиатның лицензияләнә торган эшчәнлек төре алып баруга кирәкле квалификациясе, һөнәри белеме булган, аның белән хезмәт килешүен имзалаштырган хезмәткәрләренең булуы»;

Административ регламентның («Документ формасын билгели торган норматив хокукый акт» графасы) 4 бүлеге 2 таблицасының «Төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату» бүлегенең 5 пунктын һәм «Кара металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату» бүлегенең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Россия ФСХнең 2012 елның 25 гыйнварындагы ММВ-7-6/25@ номерлы боерыгы»;

Административ регламентның 5.1.6 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Тикшерелә торган затлар таләбе буенча Министрлыкның вазыйфаи затлары үз вәкаләтләрен раслау максатларында Министрлык, контроль чаралар үткәрүгә җәлеп ителүче экспертлар, эксперт оешмалары турында мәгълүмат тапшырырга бурычлы.»;

Административ регламентның 5.1.7 пунктының унберенче абзацын, «тикшерүләр исәбе журналында» сүзләреннән соң, «(ул булган очракта)» сүзләре белән тулыландырырга;

Административ регламентның 5.1.8, 5.2.10, 5.3.9 пунктларын «Татарстан Республикасы җавап бирү актларының җыелма реестрында да.» сүзләре белән тулыландырырга;

Административ регламентның 5.2.6 пунктында:

беренче абзацны «ун эш көне эчендә» сүзләре алдыннан «дәлилләнгән соратып алу көненнән башлап» сүзләре белән тулыландырырга;

өченче абзацтагы «дәүләт контроленең башка органнары» сүзләрен «дәүләт хакимиятенең башка органнары, дәүләт мәгълүмат системалары» сүзләре белән алыштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге дүртенче абзац белән тулыландырырга:

«Кирәк булганда документар тикшерүгә экспертлар, эксперт оешмалары җәлеп ителә.»;

дүртенче – җиденче абзацларны бишенче – сигезенче абзацлар дип санарга;

Административ регламентның 5.3.5 пунктының өченче абзацындагы «электрон санлы имза белән» сүзләрен «квалификацияле көчәйтелгән электрон имза белән» сүзләренә алыштырырга;

Административ регламентка теркәлгән 2 нче кушымтадагы дәүләт функциясен үтәүнең Блок-схемасындагы соңгы гамәлне «(ул булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга.